
Печән ашат бәтигә
Бераз утын ярырсың,
Аннан суга барырсың.
– Була!- дидем фырт кына
Һәм борылдым кырт кына
Шуннан китте и китте
Мине чын солдат итте.
Бетте ялкау гадәтем,
Санаулы һәр сәгетем,
Иртүк торам, юынам,
Сөлге белән уынам.
Ялт иттерәм тешләрне
Аннан эшлим эшләрне.
Бүлмәдә тәртип хәзер,
Ни кирәксә, шул әзер
Солдат булу, шулай ул
Өйрәнгәч, бик уңай ул

**Шигырь эчтәлеге буенча сораулар:**

- Малай биленә нәрсә буган? Җиңенә нәрсә таккан?
- Йолдызлы бүрек кигәч, ул үзен кем итеп хис иткән?
- Ул ни өчән әтисе каршына килгән?
- Әтисеннән нинди фәрман алган?
- Ялкаулыгы ни өчен беткән?
- Малай ничек үзгәргән?

***Бергәләп өйрәник***



***Ватанны саклаучылар көне Әти-әниләр өчен ярдәмлек***

***(5-6 яшь)***

**Мәкальләр, әйтемнәр**:

а) Ватанга хезмәт – үзеңә хезмәт.
б) Ил тыныч булса – без дә тыныч.
в) Илдә яшисең икән – иленә хезмәт ит.
г) Батыр егет – ил күрке.
***
Дидактик уен «Таякчыклардан төзе» (танк, ракета, корабль, самолёт һ.б.).
Бабайлар, Әтиләр бәйрәме,
Ватанны саклаучылар бәйрәме.
Россия армиясендә хезмәт иткән һәм хезмәт итүче солдатлар бәйрәме
***
Солдатлар.
Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган,
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган...
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына.
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.
Клара Булатова

**Үстерешле диалог**

- Ватанны кемнәр саклый?
- Алар Ватанны кемнән саклыйлар?
- Хәрбиләрнең нинди төрләрен беләсез?
- Сезнең әтиләрегез, абыйларыгыз армиядә кем булып хезмәт иткәннәр?
- Малайлар, зур булгач, кайда хезмәт итәсегез килә? - Сез ничек уйлыйсыз, хәрбиләр нинди булалар?

**«Әйе – юк» уены**

- Самолётны кем йөртә, матросмы?
- Самолётны кем йөртә, очучымы?
- Корабльне кем йөртә, очучымы?
- Корабльне кем йөртә, матросмы?
- Танкны кем йөртә, матросмы?
- Танкны кем йөртә, танкистмы?
- Чикләрне кем саклый, матросмы?

**Тизәйткеч.** [h] авазы

Һәммә ялкау гамәлсез,
Һәм һөнәрсез, һәм гамьсез.
***

**Җырлы-сүзле уен «Күрсәт әле, үскәнем»** (солдатлар тормышы буенча).

**Шигырь уку: Җ.Дәрзаман. «Солдат булдым».**

Каеш будым билемә,
Мылтык астым иңемә
Йолдызлы бүрек кидем
– Мин солдат булдым! – дидем.
Иңемә мылтык астым,
Әти каршына бастым.
– Килдем, иптәш командир,
Әйдә, берәр фәрман бир
– Смирно! – ди әти дә,